СОВЕТ МАЛОЛЫЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ ЛЫЗИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**

« 27» декабрь 2024 ел

**КАРАР**

№ 120

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы һәм үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 56 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Кече Лызи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Кечеызи авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кечеызи авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы һәм үзара салым акчаларын җыю һәм файдалану тәртибе турындагы нигезләмәгә Татарстан Республикасы Кечеызи авыл җирлеге Советының 11.04.2014 ел, № 112 карары белән расланган (06.02.2015 ел №168, 14.11.2017 ел №135, 28.10.2022 ел №57, 27.02.2023 ел №72 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 5.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

"Җирле референдумда кабул ителгән карар нәтиҗәләрен игълан иткәннән соң, 18 яшькә җиткән барлык гражданнарга да үзара салым акчаларын түләүне өч ай эчендә башкарырга, яшәү урыны җирлек чикләрендә булган,җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләргә карамастан, үзара салым суммасының 50 проценты күләмендә ташлама билгеләнгән: 1нче һәм 2 нче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәкләрдән, сәләтсез гражданнардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, өлкән яшьтәге ялгыз пенсионерлардан, үз – үзләренә хезмәт күрсәтә алмаган гражданнардан, балигъ булмаган балаларны тәрбияләүче тулы булмаган күп балалы гаилә әгъзаларыннан, балигъ булмаган балаларны тәрбияләүче ялгыз аналардан, социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаган балалары булган гаиләләрдән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә ашыгыч яки контракт хезмәте узучы, Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, җирлек башкарма комитетының

хәбәрнамәсе нигезендә җирлек башкарма комитетының банк реквизитларын, шулай ук түләү тәртибе турындагы мәгълүматны үз эченә алган хәбәр нигезендә.».

2. Бу карар бастырылган көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет-ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлеге башлыгы А.С.Исмагилов